ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 июль 2022 ел № 3379

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләре формаларының проектларын эшләүгә, эчтәлегенә, иҗтимагый фикер алышуга, тикшерү кәгазьләренең формаларын раслауга, куллануга, актуальләштерүгә карата таләпләрне, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларын раслау турында» 2021 елның 27 октябрендәге 1844 номерлы Карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2022 елның 7 июлендәге
3379 номерлы карарына
кушымта

QR-код

## Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасы

_______________________________________ «___» _____________ 20__ ел
(контроль чараны үткәрү урыны) (кәгазьне тутыру датасы)

«____» сәг. «____» мин.
(кәгазьне тутыру вакыты)

Муниципаль торак контроле буенча
ТИКШЕРҮ КӘГАЗЕ

_______________________________________ «___» _____________ 20__ ел
(контроль чараны үткәрү урыны)

«____» сәг. «____» мин.

_______________________________________________________________________
(муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган исеме)

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________ нигезендә
(тикшерү кәгазе формасын раслау турында хокукый акт реквизитлары)

_______________________________________________________________ нигезендә
(контроль чара үткәрү турындагы карар реквизитлары һәм контроль чараның (төренең) исеме

Контроль чараның исәп номеры:
_______________________________________________________________________
(«Бердәм тикшерүләр реестры» Федераль дәүләт мәгълүмат системасында контроль чараның номеры һәм исәп номеры бирү датасы)

Контроль чара үткәрүче вазыйфаи затлар
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(контроль чараны үткәрүче вазыйфаи затларның вазыйфалары, фамилияләре һәм инициаллары)

Контроль чара үткәрелә торган контроль объекты:

_______________________________________________

Гражданның яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда), аның салым түләүченең идентификация номеры һәм (яки) шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәү номеры, гражданны яки шәхси эшмәкәрне теркәү адресы, юридик затның исеме, аның салым түләүченең идентификация номеры һәм (яки) төп дәүләт теркәү номеры, контрольдә тотыла торган зат булып торучы оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) адресы: _______________________________________________

_______________________________________________

_______________________________________________

Контроль объекты: _______________________________________________

(юридик затның исеме, гражданның яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда)

_______________________________________________

(юридик затның, шәхси эшмәкәрнең эшчәнлек төре, производство объекты, куркыныч төре, характеристикасы, категориясе, куркынычлылык классы)

Адрес:

_______________________________________________

(тикшерү кәгазен тутырып, контроль чараны үткәрү урыны һәм (яки) юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан файдаланыла торган объектларны күрсәтү)

Чикләүләр:

_______________________________________________

(Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясе субъекты законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләр нигезендә контроль чараны үткәрү предметын чикләүгә күрсәтмә)

Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы, аларга җаваплар юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан тикшерү предметын тәшкил итүче мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен яки үтәлмәвен ачык күрсәтә торган сораулар исемлеге:

| № т/б | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар | Структур берәмлекләрен күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне билгели торган норматив хокукый актлар реквизитлары | Сорауларга җаваплар | | | Искәрмә («кулланылмый» графасын тутырган очракта тутырыла) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | кулланылмый | |
| 1. | Торак фондыннан файдалануга һәм аларның сакланышына карата таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 17, 30, 67 статьялары, Россия Төзелеш министрлыгының 2021 елның 14 маендагы 292/пр номерлы боерыгы белән расланган Торак урыннардан файдалану кагыйдәләренең 5, 6, 16 пунктлары | | | | |
| 2. | Күпфатирлы йорттагы гомуми файдаланудагы бүлмәләрне (гомуми милекне) карап тотуга, файдалануга һәм аларның сакланышына карата таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 36 статьясы, Россия Төзелеш министрлыгының 2021 елның 14 маендагы 292/пр номерлы боерыгы белән расланган Торак урыннардан файдалану кагыйдәләренең 6 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертеләме? | РФ Торак кодексының 153 статьясы | | | | |
| 4. | Күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлегенә карата таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161, 161.1, 162, 164 статьялары, | | | | |
| 5. | Идарәче оешманың күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе бармы? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1.3 пункты | | | | |
| 6. | Күпфатирлы йортларны техник тикшерү тәртибе үтәләме? | Россия Дәүләт Төзелеш министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.1 пункты | | | | |
| 7. | Торак фондын агымдагы ремонтлауны оештыру һәм планлаштыру тәэмин ителгәнме? | Россия Дәүләт Төзелеш министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.3 пункты | | | | |
| 8. | Торак фондын сезонлы эксплуатацияләүгә әзерләү тәэмин ителәме? | Россия Дәүләт Төзелеш министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.6 пункты | | | | |
| 9. | Диспетчерлык һәм авария-ремонт хезмәтләрен оештыру һәм эшләтү тәэмин ителгәнме? | Россия Дәүләт Төзелеш министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 2.7 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрне һәм йорт яны территорияләрен карап тоту тәртибенә карата таләпләр үтәләме? | Россия Дәүләт Төзелеш министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының III кисәге | | | | |
| 11. | Күпфатирлы йортларның төзелеш конструкцияләренә техник хезмәт күрсәтүне һәм ремонтлауны гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр үтәләме? | Россия Дәүләт Төзелеш министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының IV кисәге | | | | |
| 12. | Күпфатирлы йортлардагы инженерлык җиһазларына техник хезмәт күрсәтүне һәм ремонтлауны гамәлгә ашыру тәртибенә карата таләпләр үтәләме? | Россия Дәүләт Төзелеш министрлыгының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының V кисәге | | | | |
| 13. | Күпфатирлы йорттагы яки торак йорттагы торак милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча таләпләр үтәләме? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы торак милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы Карарының 11 кисәге | | | | |
| 14 | Күпфатирлы йортның энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар үткәрү турында таләпләр үтәләме? | 2009 елның 23 ноябрендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясының 4 өлеше | | | | |
| 15. | Күпфатирлы йортларда инвалидлар өчен бүлмәләргә керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр үтәләме? | | | | | |

Исемлектәге сораулар буенча аңлатмалар һәм өстәмәләр:

________________________________________________________________

________________________________________________________________

Контроль чараны үткәрүче затның (затларның) имзалары:

________________________________________________________________

Вазыйфасы, Ф.И.А.и.

________________________________________________________________

Вазыйфасы, Ф.И.А.и.

________________________________________________________________

Вазыйфасы, Ф.И.А.и.

________________________________________________________________

Вазыйфасы, Ф.И.А.и.

Тикшерү кәгазе белән таныштым:

________________________________________________________________

(җитәкченең, башка вазыйфаи затның яки юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«____» ________________ 20__ ел ________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазе белән танышудан баш тарту турында билге:

________________________________________________________________

(контроль чараны үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«____» ________________ 20__ ел ________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазенең күчермәсен алдым:

________________________________________________________________

(җитәкченең, башка вазыйфаи затның яки юридик затның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«______» ________________ 20__ ел ________________________________________

(имза)

Тикшерү кәгазен алудан баш тарту турында билге:

________________________________________________________________

(контроль чараны үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затның (затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«_____» _____________ 20__ ел ________________________________________

(имза)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева